**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУМБУТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422664, с. Шомбыт,
ул. Советская, дом 18

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШОМБЫТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422664, Шомбыт авылы,
Совет урамы, 18 нче йорт,

**Тел.: (84361) 33100, факс: (84361) 33100, e-mail: Smb.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru**


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2023 Шомбыт авылы №7

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2022 елның 28 ноябрендә узган Шомбыт авылы гражданнар җыенында кабул ителгән 1,2 номерлы; Шестая Речка авылы гражданнар җыенында кабул ителгән 1,2 номерлы узган карарларын тормышка ашыру максатында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомбыт авылы, Совет урамы, 18 йорт; Шомбыт авылы, Завод урамы, 22 йорт; Шестая Речка авылы, Лесная урамы, 6 йорт адреслары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры Сибгатуллина А.К. йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомбыт авыл җирлеге башлыгы Н.Е.Сергеев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Шомбыт авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2023 елның
08 февралендәге 7 номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**“Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә**
**гражданнарның үзара салым акчаларын җыю**
**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан (белем алуның көндезге формасында укучы студентлардан гайре, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артык була алмый) җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә
2023 елның 28 фераленә кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә бланкы (әлеге Тәртипкә кушымта) гражданнар игътибарына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итү һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (халыкка белдерү) ысулы белән, шулай ук кул куйдырып тапшыру юлы белән яисә почта аша юллап җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шомбыт авыл җирлеге”муниципаль берәмлегенең лицевой счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр акча средстволарын физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган, почта переводларын (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аркылы яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы булып керем (приход) касса ордерының тамганамәсе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
“Шомбыт авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
җыю Тәртибенә КУШЫМТА

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы “Шомбыт авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча
бер тапкыр түләнелә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ №_________

Түләүченең Ф.И.А.
______________________________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________
______________________________________________________________нигезендә
Сезгә 2023 елның 28 февраленә кадәр үзара салым чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр түләнелә торган 1000 сум күләмендәге түләүне түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:
УФК по РТ (Финансово-бюджетная палата Рыбно-Слободского муниципального района)
Банк получателя БИК 019205400
Сч. № 03231643926504641100 в ОТДЕЛЕНИЕ – НБ Республики Татарстан Банка России//УФК по Республике Татарстан г. Казань к\сч 40102810445370000079
Получатель УФК по РТ (Финансово-бюджетная палата Рыбно-Слободского муниципального района) ИНН 1634005064 КПП 163401001
КБК 81111714030100000150 ОКТМО 92650464
Назначение платежа: Средства самообложения граждан, зачисляемые в бюджеты сельских поселений

Җитәкче _________________ _______________________________________
М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнелә торган _________________сум күләмендәге түләүне түләү турында ХӘБӘРНАМӘ №_________
Түләүченең Ф.И.А.и. _______________________________________________________
Адрес:_____________________________________________________________________
Алдым “__ __” ________________, 20__ ел

_______________________________________
(түләүченең имзасы)
*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта ертып алына торган төпсә тутырыла һәм Шомбыт авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*